СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**13 декабрь, 2024 ел** **№ 472**

**Биектау муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 221 номерлы карары белән (Биектау муниципаль районы Советының 23.09.2020 № 5, 12.11.2021 № 28.06.2024 № 419 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган тәртиптә билгеләнә торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2025 елның 1 июленнән арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмалары

структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладын күләмен 1,05 тапкыр индексларга һәм аны 13 990 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанс һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамөтдинов